| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВЕРХНЕСЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |

422015 Республика Татарстан Атнинский район с. Верхняя Серда Тел. 3-28-70

"30" март 2021 ел.

КАРАР № 5

2016 елның 21 декабрендә кабул ителгән «Дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, төзелеш белән бәйле булмаган максатлар өчен, бердәнбер мөрәҗәгать итүчегә" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" гы 14 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27.07.2010 елдагы 210-ФЗ номерлы Федераль закон (2017 елның 29 декабрендәге 438-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләр белән), "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның 21 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган «Дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, төзелеш белән бәйле булмаган максатлар өчен, бердәнбер мөрәҗәгать итүчегә» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү:

1.1. 2.6 пунктының 15,16 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;"»

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы хокукый мәълүматынын рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Югары Сәрдә авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе: Хөснетдинов Р.Р.